Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!



Сабантуй

18 апрель, 1995 ел.
№ 29
(4643)

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ





Җиңүнең 50 еллыгына багышланган сәнгать фестиваленнән күренешләр: 1. Танылган нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов. 2. Күренекле җырчы Шамил Әхмәтҗанов кызы Чулпан белән.

М. ШАКИРҖАНОВ фоторәсеме.

ОЗАК ЯШӘГЕЗ, ВЕТЕРАННАР!

БЕЗ, 5 сыйныф укучылары, мәктәптә үткәрелә торган тарих түгәрәгенә йөрибез. Бу түгәрәктә хәзерге вакытта авылда яшәүче сугыш ветераннарының тормыш юлын өйрәнәбез. Әгәр алар авыл Советыннан, я совхоздан ярдәм сорасалар, без авыл Советына хәбәр итәбез.

Бер көнне мәктәптә «Кайгырту» операциясе игълан иттек. Бу көнне без берничә ветеранның өендә булдык. Шунысы кызык, 100 яшьлек Әхмәтша бабай әле рәхәтләнеп интервью бирә ала, үзенең сугышчан юлын сөйли. Ул гражданнар сугышында, Бөек Ватан сугышында катнашкан. Аның ике сугышта катнашып та, шулай озак яшәве күпләрне сокландыра.

Ветераннар белән очрашып, үзебез дә бик күп белем алабыз. Ул сөйләшүләр безгә туган ягыбызны тирәнрәк өйрәнүгә бик нык ярдәм итә.

Резидә ГАЛИЕВА,
Венера ИСМӘГЫЙЛОВА.
Тукай, Иштирәк.

Без–җиңүчеләр токымыннан!



ҺӘРВАКЫТ БУЛСЫН КОЯШ!

БЕЗ авылның «Гөлбакча» исемле балалар бакчасына йөрүчеләр белән берлектә Җиңүнең 50 еллыгына багышланган кичә үткәрдек. Башта рәсемнәр ярышы оештырдык. «Кирәкми безгә сугыш!», «Туплар атылмасын!», «Яшәсен тынычлык!» дип язылган плакатлар элдек. Муса Җәлилнең «Вәхшәт» исемле шигырен сәхнәләштердек. «Яу кырында» дигән җырны бик матур җырладык. Укытучыбыз Динә апа Вәлиуллина һәм тәрбияче Мәдинә апа Зарипова безгә төрле-төрле шигырьләр, җырлар һәм биюләр өйрәттеләр. Сугышта үлгән кешеләрне бер минутлык тынлык белән искә алдык. Кичәбезне йолдыз фигурасы ясап, кулларыбызга нәни әләмнәр тотып, «Һәрвакыт булсын кояш!» дигән җыр белән тәмамладык. Мәктәбебезнең директоры Рәисә апа Вәлиуллина безгә зур рәхмәт әйтте. Күгебез гел шулай аяз булсын, кояш гел елмайсын иде.


I сыйныф укучылары.
Чирмешән, Иске Кади.

ТОРМЫШНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕРГӘ

Сугыш башлангач, ат җигеп кырда эшли, тырмалый, ашлык чәчә Миңсылу әбием. Көзләрен, ашлыкны җыеп алгач, үзләренә булмаса да, ашлыкны ат җигеп фронтка җибәргәннәр. Кышкы озын кичләрдә, кич утырып, сугышчыларга җылы бияләй, оекбашлар бәйләп җибәргәннәр. Кышкы салкыннардан курыкмыйча, атналап, айлап урман кискәннәр. Алар әзерләгән утыннарны поездларга ягулык итеп кулланганнар. Эш авыр, салкын дип тормаганнар, иртәдән кичкә кадәр бөтен көчләренә тырышып эшләгәннәр. Әле аның өстенә кияргә киеме, туйганчы ашарына булса икән! Никадәр авыр булса да, җиңү өчен көчләрен кызганмаганнар.

Сугыш елларының авырлыгын әбием әле дә онытмый. Безне тыныч, тук тормышның кадерен белергә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтә.

Гөлназ СӘЕТОВА.
Кукмара, Туембаш.



Таныш булыгыз!

КАЗАН кызы Альбина ШАКИРОВА Островский урамындагы «Сөембикә» исемле татар балалар бакчасына йөри. Тиздән аңа 7 яшь тула. Һәм ул быел мәктәпкә укырга барырга әзерләнә. Теләге — үзләре яшәгән урамдагы 39 нчы мәктәптә белем алу. Ул мәктәптә татар һәм урыс теле белән бергә чит телләрне дә өйрәнәләр. Ә Альбинаның бигрәк тә инглиз телен өйрәнәсе килә. Ул шулай ук төрек һәм гарәп телләрендә дә укырга хыяллана.

Альбина биш яшеннән 1 нче музыка мәктәбенең әзерлек классында укый. Мәктәпкә бик теләп, яратып йөри. Хәтта үзе көйләр дә иҗат итә. Композитор А. Руденко аны үзенең композиция классына алды.

Альбина әдәбиятны да ярата. Балалар өчен чыккан яңа китаплар белән танышып бара. Шигырьләр ятлый. Үзе дә шигырьләр, әкиятләр уйлап чыгара, рәсемнәр ясый.

Бүген без укучыларыбыз игътибарына Альбина Шакированың бер әкиятен һәм Фирая Зыятдинова шигыренә иҗат иткән җырын тәкъдим итәбез.



БОРЫН-БОРЫН заманда бер авылда яшәгән ди ике үрдәк. Үрдәкләр — ак үрдәк белән кара үрдәк булганнар.

Бер вакыт ак үрдәк елга буена су коенырга төшеп киткән.

Бу вакытта яфракта бакылдап бер бака утыра икән. Ак үрдәк аның янына килгән дә, аптырап калган. Ул моңарчы баканы күргәне булмаган икән.

— Син кем?— дип сорагач, бака әйткән:

— Мин — Бака «Бакбак»,— дигән.

Аннан соң Бака суга сикергән һәм юкка чыккан. Ә үрдәк «Бакбак», дип кычкырып аны эзләп йөри икән. Шуннан соң үрдәк һәрвакыт «Бак-бак» дип кычкырып йөри башлаган ди.

Әкият тә шуның белән беткән.



А. ШАКИРОВА кое
Ф. ЗЫЯТДИНОВА шигыре

Яз килә, яз көлә —
Йөзләрдә елмаю,
Кояшым, алтыным,
Сип әле нурларың!

Сип әле нурларың —
Тамчылар биесен,
Яз биргән җиркәем
Чәчәккә күмелсен.

Кыш буе йоклаган
Гөлкәем терелсен,
Елмаеп кояшка,
Яктыга үрелсен.

Карачы бер генә:
Бар дөнья көлә ич.
Көлмәскә, гөр килеп,
Яшел яз килә ич!



Безнең яраткан әдипләребез

Разил Вәлиев



ӘДИП ТУРЫНДА

Разил Вәлиев — танылган язучы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Халык аның җырларын бик яратып тыңлый, тыңлап кына калмый, отып алып, үзе дә җырлый. Татарстанның халык депутаты буларак Разилнең һәрвакыт төпле фикере, саллы сүзе бар. Бәлки, кайчакта Разил хискә бирелеп, шагыйрьләрчә кайнарланып та киткәлидер. Әмма шунысы ачык: ул һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән халык язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, туган мәдәниятебез, телебез, гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырыша.

Минтимер ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасы Президенты.

* * *

Начар кешедән яхшы шагыйрь, яхшы язучы чыга алмый торгандыр. Разилнең шигырьләрен, җырларын тыңлаганда, проза әсәрләрен укыганда мин шул турыда уйладым. Аның һәр әсәре халкыбыз язмышы өчен борчылып язылган, алар халкыбыз бәгыреннән өзелеп төшкән сыман.

Разил — моңлы, җырлы, уйлы егет. Көне-төне шигырь-җыр, повесть-пьеса гына язып утырса да, ул халкыбыз өчен бик зур эш эшләр иде. Ләкин кыю шәхесләр һәрчак фидакарь көрәшче дә була. Разилне мин халык язмышы өчен янып яшәүче иң фидакарь язучыларыбызның, көрәшче егетләребезнең берсе дип саныйм.

Илһам ШАКИРОВ,
Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.

* * *

Разил Вәлиевнең җырлары үзләренең тирән эчтәлеге, гаҗәеп дәрәҗәдә моңга һәм хискә бай булулары белән халыкның төрле катлаулары тарафыннан яратып кабул ителде, аның бәхет һәм азатлык өчен көрәшендә рухи көч бирде, халыкны эстетик, әдәп канунлары рухында тәрбияләүгә дә, аңа ләззәт бирүгә дә хезмәт итте һәм итеп килә. Бу җырлар чын мәгънәсендә халык күңелләрен тибрәтә ала...

Әмма Разил Вәлиев күп куйган шагыйрь гына түгел. Ул — әсәрләре зур уңыш белән татар сәхнәсендә баручы танылган драматург та, күренекле прозаик та, әдәби, иҗтимагый тормышыбызда актив эшләүче кыю йөрәкле җәмәгать эшлеклесе дә...

Әбрар КӘРИМУЛЛИН,
язучы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы.

* * *

Татар поэзиясе бик бәхетле: шигърияткә ел саен күпләгән кеше килеп тора. Шул күпләгәннәр арасында игелекле талантлар да күренгәләп ала. Разил Вәлиев әнә шундыйларның берсе. Мин аны яшьлек җырчысы дияр идем.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты,
Татарстанның халык язучысы.

* * *


Разил Вәлиевне шагыйрь буларак та, кеше буларак та бик күптән беләм. Аның белән бергәләп иҗат иткән җырыбыз «Ядкарь»га озакламый утыз яшь тула. Аңа характеристика бирергә кушсалар, мин берничә сүз белән генә болай дип әйтер идем: «Разил — гаҗәеп затлы, киң күңелле, олы җанлы, чын мәгънәсендә иманлы кеше». Аның белән әңгәмә кору да, эш эшләү дә, иҗат итү дә рәхәт. Разилне күргәч, аның белән сөйләшеп утыргач, бөтен кайгыларың онытылып, яшисе килә башлый. Мин гомерем буе елаксытык кешеләрне сөймәдем. Үзем хис кешесе булсам да, нык холыклы кешеләр тирәсенәрәк елышырга тырыштым. Разилнең исә уйлары да, кылган гамәлләре дә, холкы да ныклы һәм иple...

Фасил ӘХМӘТОВ,
композитор, Татарстанның Г. Тукай исемендәге,
Россиянең М. Глинка исемендәге
Дәүләт премияләре лауреаты, Россиянең халык артисты.

* * *

Разил Вәлиевне мин моңа кадәр бик тә моңлы, бик тә мәгънәле җырлар язучы шагыйрь буларак белә идем. Ватаннан еракта яшәүче татар баласының милли моңга сусавын, сагынуын басса да беразга татар җыры, моңлы җыр гына баса ала[дыр]. [Ма]шинага утырып, юлга чыгуга, мин иң беренче эш итеп магнитофонга татар җыры язылган кассета куям. Шул җырларны тыңлый-тыңлый инде ничә еллар буе мин Америка юлларын гизәм, шул җыр канатына утырып, туган якларга, Ватаныма кайтып киләм.

1991 елда беренче мәртәбә Казанга килгәч, мин инде ничәмә-ничә еллар тыңлап йөргән шул җырларның авторы шагыйрь Разил Вәлиев белән таныштым һәм, үзем дә сизмәстән, дуслашып та киттем. Тора-бара мин аның күңелне кузгата торган җырлар язучы шагыйрь булуы өстенә, милләт кайгысын кайгыртучы олы шәхес, Татарстанның дәүләтчелеген аякка бастыру өлкәсендә көн-төн эшләүче җәмәгать эшлеклесе дә икәнлеген үз күзләрем белән күрдем.



ҮЗГӘРЕРГӘ!

Җанны талкый һаман заман уе,
Төште инде сагыш йөзләремә...
Яшәп булмый элек яшәгәнчә,—

Гашыйк идем язгы бураннарга,
Гашыйк идем җәйге рәшәләргә.
Исемемне онытмаслар әле
Гашыйк җаннар җирдә яшәгәндә.

Мин киткәч тә дөнья матур булыр,

ТОРМЫШ ЮЛЫ

РАЗИЛ ИСМӘГЫЙЛЬ УЛЫ ВӘЛИЕВ 1947 елның 4 гыйнварында Татарстанның Түбән Кама районы Ташлык авылында туган. 1965 елда Түбән Кама урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә, аннары Мәскәүдәге әдәбият институтында югары белем ала. 1972-1981 елларда Казанга кайтып, «Ялкын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы секретарь эшләрен башкара. 1981-1984 елларда Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы җаваплы секретаре булып эшли. 1984 елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары итеп сайлана. 1986 елдан бирле — Татарстан Милли китапханәсе директоры.

Р. Вәлиев шигырьләр, повестьлар, драма әсәрләре иҗат итә, әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнә.

1982 елда «Яшисе килә» повесте өчен Р. Вәлиевкә Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелде. Ул шулай ук Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемне йөртә.

БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ:

1. Беренче карлыгачлар: яшь шагыйрьләр җыентыгы. 1968.
2. Зәңгәр кабырчыклар. Шигырьләр. 1971.
3. Хыялый Мияубикә. Балалар өчен шигырьләр. 1976.
4. Яшен тамыры. Шигырьләр. 1977.
5. Без — Кояш балалары. Балалар өчен шигырьләр. 1981.
6. Яшисе килә. Повестьлар. 1982.
7. Күкләр биек. Очерклар, публицистик язмалар. 1983.
8. Ядкарь. Шигырьләр. 1987.
9. Мирас. Повестьлар. 1990.
10. Бер алманы бишкә бүләек. Җырлар. 1992.
11. Кайтаваз кайда яши? Балалар өчен шигырьләр. 1984.
12. Кышкы учак. Шигырьләр. 1994.

УРЫС ТЕЛЕНДӘ:

13. Жить хочется! Повести татарских писателей. 1983.
14. Определение любви. Стихотворения и песни. 1984.
15. Жить хочется! Повести. 1986.
16. Жить хочется! Повесть. Москва. 1989.

ТӘРҖЕМӘЛӘР:

17. К. Дойль. Баскервильләр эте. Повесть. «Ялкын» журналы. 1974. 11-12 саннар.
18. Р. Киплинг. Маугли. «Ялкын» журналы. 1976. 10-12 саннар.
19. С. Экзюпери. Нәни принц. 1978.
20. Тылсымлы чишмә. Дөнья халыклары әкиятләре. 1984.
21. Иң озын әкият. Дөнья халыклары әкиятләре. 1994.

СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ:

1. Әйдә барыйк, кызлар карыйк. Музыкаль комедия. 1989 елда К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында куелды.
2. И машина, машина, җитте минем башыма... Музыкаль комедия. 1990 елда К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында куелды.

* * *

Разил Вәлиев — бәхетле әдип. Ул, башка яшь язучылар кебек, укучылык, өйрәнчеклек чорын бөтенләй диярлек кичермәде. Олы әдәбият дөньясына үз тавышы, үз темасы, үз тәэсирләре белән яшен ташыдай бәрде дә керде.

Разил актив иҗат итү белән бергә һәрчак җаваплы эшләр башкарды. Һәр җирдә үзен сәләтле оештыручы, кешеләр белән уртак тел табып эшли белүче буларак таныттгы.

Мәхмүт ХӘСӘНОВ,
язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге
Дәүләт бүләге лауреаты.

Сулдан уңга: Р. Вәлиев, Г. Моратов, Н. Дәүли, Х. Вәлиәхмәтов.

Сулдан уңга: Р. Вәлиев, Р. Ишморат, А. Шамов.



Р. Вәлиев А. Хәмзин белән.

Яшен булмыйм элек яшәгәнчә.
Таң шәфәгы минем күзләремдә.
Нур өстисем килә туар көнгә...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Нур өстисем килә туар көнгә,
Нур саласым килә сүзләремә.
Итәгемнән тарта үткән төннәр...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Итәгемнән тарта кара төннәр...
Ышаналмыйм кайчак үзәремә.
Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Басмак булам заман эзләренә.
Алдан бара әйдәп фидаилар...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Алдан бара әйдәп фидаиллар.
Иярттерләр микән үзләренә?
Җанны талкый һаман заман үе:
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!

БЕР КАЙТЫРМЫН ӘЛЕ...

Сибгат Хәким истәлегенә

Кытлык булмас җирдә шагыйрьләргә,
Туу белән үлем булган чакта.
Чәч агаргач шигырь язып кара...
Һәркем шагыйрь юләр балачакта.

Еллар йөгә баскач иңнәреңә
Очып кара хыял канатында.
Гомер буе җыйган байлыгыңны
Син чәчәргә тиеш, таратырга.

Ай-кояшка тиңдәй Тукай барда,
Туфан барда шагыйрь булып кара...
Охшатам мин моңлы язмышымны
Кояш нуры иңгән болытларга.

Сулдан уңга: җырчы М. Сөнгатуллин, Р. Вәлиев, баянчы Р. Сәләхов.



Ышанмагыз минем үлемемә.

БАЛАЧАГЫМ

Ага чишмә җырлап,
Белми талачагын...
Чишмә җыры төсле
Булсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә,—
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Беләм җанда мәңге
Әни калачагын.
Әти-әни белән
Узсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә,—
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Яңып яшим җирдә,
Минем янар чагым.
Кояш сыман көләч
Булсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә,—
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Беләм бәхет эзләп
Юллар салачагым...
Ватан куенында
Узсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә,—
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Сулдан уңга: Р. Гатауллин, Т. Миңнуллин, Ч. Айтматов, М. Госманов, Р. Вәлиев.


Сулдан уңга: үзбәк халык язучысы Әсгать Мохтар, Р. Вәлиев, Башкортстанның халык шагыйре М. Кәрим.



Сулдан уңга: утырганнар — Ә. Кәримуллин, М. Мәһдиев; басканнар — И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, М. Госманов, Р. Вәлиев.

Кайтыйм әле балачагыма

«...Язмышымны канат итеп, Яшьлектән кайтып киләм»



ГОМЕРЛӘРЕ буе юлда, төрле авылларда, шәһәрләрдә йөреп, татар халкына культура хезмәте күрсәткән, күңелләргә ак юл салган беренчә фидакарь аксакалларыбыз бар безнең. Шундыйларның берсе — Әзәл ага Яһүдин. Яшь буын вәкилләре, бәлки, аны тиешенчә белеп тә бетерми торганнардыр дип, Әзәл аганы редакциягә чакырдык, иркенләп бер сөйләшеп утырдык. Әңгәмәнең бер өлешен сезгә дә тәкъдим итәбез.

— *Әзәл ага, сезнең балачак революциягә кадәрге елларга туры килә бугай?*

— Дөрес. Мин гасыр башында — алтынчы елда, Базарлы Матак волосте, Спасс өязе, Яңа Чаллы авылында дөньяга килгәнмен. Әти — Бәдретдин хәлфә, авылда, иске мәдрәсәдә укытучы булып эшли иде. Мин дә белем алуны иман шартыннан башлап җибәрдем. 1915 нче елдан соң гына җәдитчә уку (җәгъръәфия, хисап) кертелде. Аңарчы гел «әлепби-ти-си»ләрне ятладык. Җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында бик каты көрәш барды ул елларда. Җәдитчә укый башлагач, кара тактаның ни икәнлеген белдек. Тукайны өйрәндек.

Шул унбишенче елны әти, кинәт каты гына авырып китеп, вафат булды. Без әни тәрбиясендә үстек. Ул да гомере буе балалар укытты. Шуңлыктан өйдәге китапларның исәбе-хисабы юк иде. Минем бертуган абый — Габделәхәткә китапның җене генә түгел, шайтаны кагылган булгандыр. Әни аны кибеткә шикәр, ипи алырга җибәрсә дә, ул китап күтәреп кайта иде. Миңа да күчте ул «китап җене».

— *Артист тормышына омтылу бала чакта ук бар идеме?*

— Малай чакта дус малай-кызлар белән бергәләп «Кызлар шулай кызык итәләр» дигән пьесаны өйдә, өстәл астында куйганны хәтерлим мин үзе... Ә егет булып җитешкәч, 1927 елда, Казанда татар театры техникумына укырга кердем. Совет властеның оешкан еллары. Татар зыялылары күп кирәк. Әмма бик авыр хәлдә укыдык. Әни авылда, энем яшь, ат юк. 8 сум гына стипендия алабыз. Хәтта мунча керергә дә акча җитешми... 30 нчы елларда бездән, бер төркем 4 нче курс студентларыннан, бер сәнгать бригадасы төзеп, Казан тирәсе авылларына җибәрделәр. Бу — үзенә күрә колхозлашуны агитацияләү булып торды. Шул 30 нчы елдан минем озын иҗат юлы башлана да инде.

— *Әзәл ага, безнең буын вәкилләре белә торган нинди артистлар белән эшләргә туры килде?*

— Ул замандагы бөтен атаклы шәхесләр белән концертлар куйдым бугай инде: Рәшит Ваһапов белән бик



дуслар идек, Фәхри Насретдинов, Усман Әлмиев, Сара Садыйкова, Венера Шәрипова, Зиннур Нурмөхәммәтовлар белән дә күп гастрольләрдә бергә булдык. Мин йөргән шәһәр-авылларны картада билгеләсәң, Ленинград белән Чита арасында зур бер территория барлыкка киләчәк. Кайвакыт чыдамаслык авыр хәлдә дә кала идек: бату, чуму, салкын клубларда куну... Түзгәнбез, бирешмәгәнбез алай да.

— *Ярдәм итүчеләр юк идеме?*

— Менә Мәскәүдән кайткан мәртәбәле артист Гали ага Ильясовны хәтерлим әле. Ул, татар артистларын халык каршында мескен итеп күрсәтергә теләмәде. Авылга туңып, бөрешеп килеп керсәләр, халык аларны кызганса, ничектер артист халкының дәрәҗәсе төшә. Гали ага, һәм артистка җылы тахап (сырган чалбар-телогрейка), кием-салым, хәтта юл кроватьларына кадәр алып бирде. Аның программасында һәркем бер уен коралында уйный белергә тиеш иде. Әнә шулай сәнгать өчен янып-көеп йөрүче зат иде Гали ага.

— *Әзәл ага, элекке җырчылар белән хәзергеләр арасында нинди аерма сизәсез?*

— Мин үзем бераз консервативрак кеше. Яшьләр үпкәләмәсен. Үзем моңлы көйләрне яратканлыктан, хәзерге яшьләрнең көйсез «речетатив» такмаклар җырлавы ошамый. Аларда ни моң, ни мәгънә. Менә шулардан риза түгелмен.

— *«Сабантуй»ны укучыларга нинди теләкләрегез бар?*

— Форсаттан файдаланып әйтим әле. Кайсы гына мәктәпкә барсаң да, Тукайның шигырьләрен начар беләләр. Аның шигырьләре бит «Туган тел» белән генә чикләнми. Менә шуңа күбрәк игътибар бирсеннәр иде!

Әзәл ага тугызынчы дистәне ваклаca да, тыныч кына өендә ятмый — Татарстан дәүләт фольклор үзәгендә гыйльми хезмәткәр буларак иске язуларны укый, өйрәнә, фәнгә кыйммәтле табып китерә. Саубуллашканда кайчандыр репертуарында булган шигырьдән бер өзек укыды ул:

«... Язмышымны канат итеп,
Сезнең белән очрашырга
Яшьлектән кайтып киләм...»

Картаерга бер дә ашыкмый әле Әзәл ага Яһүдин. Киләчәккә зур өметләр баглап яши. Эшлисе эшләре дә күп әле аның, бик күп!

А. ГЫЙМАДИЕВ.

Рәсемдә: Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романы буенча сәхнәләштерелгән «Шаһиевның өйләнүе» дигән өзектә Ә. Яһүдин — сулдан беренче. 1970 еллар.

Без — җиңүчеләр токымыннан



САДЫЙК бабай белән Миңнур әбинең күз нуры итеп күргән ике генә баласы — Мөнир белән Әхмәтнурлары бар иде. «Иде» дип әйтү үзәкне өзсә дә, чынбарлык шуннан гыйбарәт... Бу егетләр хакында авылда: «Кызлар кебек матурлар, холыклары да бик әйбәт, бәхетле генә булсыннар»,— ди торганнар иде. Шулаен-шулай да, миллионнарның бәхетен сугыш афәте юк итте дә куйды. Ул хакта сүз алда булачак...

Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, башта Мөнир, аннан соң Әхмәтнур абый Бөре педучилищесына (Башкортстан) укырга керделәр. Бу очраклы хәл булмагандыр. Чөнки ул чакларда авылда иң абруйлы кешеләр укытучылар иде. Шуны хәтерлим: укытучы урам буйлап килә икән, ничектер аның күзенә күренмәскә тырыша идек. Начар укыган өчен түгел, ул яктан әткәй-әнкәй, туганнарның йөзен кызартмадык. Хикмәт башкада: укытучыны искиткеч хөрмәт итүдә. Халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев үзенең бер әсәрендә укытучының ял бүлмәсендә ашап утыруын күреп егылып китә язуын әйтә. Әдип тулысынча хаклы. Әйе, без дә укытучыны ниндидер ашамый-эчми торган фәрештәгә тиңли идек. Бу инде өлкәннәрдән, әткәй-әнкәйдән килә...

Мөнир абый укыта башлаган иде, күп тә тормый армиягә алалар. Ерак Көнчыгышта Хасан күле тирәсендә хезмәт итте. Әхмәтнур абыйны да сугыш башланырга бер ел калгач хәрби училищега укырга җибәрделәр.

... Җәй авылга кайтканда, иң беренче булып Садыйк бабай белән Миңнур әбине күрергә керәм. Эчемдә утырса да сер бирмәскә тырышам. Күңел бит ул, әгәр бу сугыш булмаса, әби белән бабай карт көннәрендә икәү генә калмаслар, абыйлар өйләнерләр, ә картлар оныкларын сөеп туймаслар иде дип уйлыйм. Ләкин хәзер болар — буш, тормышка ашмас хыял гына. Нәрсә соң бу — ачы язмышмы, диктатор җитәкчеләренең алдан күрә белмәү нәтиҗәсеме? Сугыш башланыр алдыннан булган 10 елга анализ ясасаң, сугышны булдырмый калу мөмкинлеге булган дияргә туры килә...


Документларга ышансак, Мөнир абый турында шулар мәгълүм: ул хезмәт иткән танклар дивизиясе сугышны чик буенда каршылый. Билгеле сәбәпләр аркасында, дивизия сугыша-сугыша, контратакалар ясый-ясый, чигенергә мәҗбүр була. Бу вакытта илнең язмышы кыл өстендә генә тора. Дошман Мәскәүгә бөтенләй якыная, немец генераллары бинокльдән шәһәрнең урамнарын күзәтәләр. Фашистлар башкалабызны алу өчен бик күп көч туплыйлар. Кышкы салкыннарга кадәр шәһәр алынып, анда немец армияләренең парады үткәрелергә тиеш була. Кызыл мәйданда Гитлерга һәйкәл салынып, немец сугышчылары аңа чәчәкләр салырга әзерләнәләр. Ләкин Мәскәүне алу өчен Тула һәм Калинин тирәсендә фронтны өзәргә кирәк була. Ләкин безнең сугышчылар моңа юл куймыйлар. Рота командиры өлкән лейтенант Мөнир Мөхәммәтдиновның танкистлары Калинин шәһәрендә арысландый сугышалар, дошманның күп кенә машиналарын юк итәләр. Ләкин сугыш корбаннарсыз булмый: бер каты бәрелеш вакытында Мөнир абый экипажы белән бергә һәлак була. Орден, медальләрен район хәрби комиссариаты аша әти-әнисенә тапшыралар. Бу кыйммәтле бүләкләр хәзер мәктәпнең туган як музеенда саклана. Батыр офицерга багышланган стендка аның фоторәсеме куелган. Матур, озын буйлы татар егете. Күкрәгендә — дәүләт бүләкләре...

Музейның икенче бер стендында Әхмәтнур абыйның зурайтылган рәсеме. Абыйсы кебек үк чибәр, күркәм, бөтенләй яшь... Ул да сугышның беренче көннәреннән үк фронтта була. Яралана, госпитальләрдә ята. Яңадан фронтның алгы сызыгына китә. Пулеметчылар (сугыштагы иң хәтәр урындагылар, чөнки һөҗүмгә күчәр алдыннан, дошман иң элек каршы якның пулемет ояларын юк итә, шунсыз атакага күтәрелә алмый...) ротасы командиры капитан Әхмәтнур Мөхәммәтдинов сугышчылары Төньяк Кавказны азат иткәндә аеруча зур батырлыклар күрсәтәләр. Ул өйрәткән снайперлар (капитан Мөхәммәтдинов дивизиядә снайперлар мәктәбе оештыра һәм шуңа җитәкчелек итә) шактый немец офицерларының башына җитәләр. Үзе дә 40 фашист илбасарларын юк итә. Орденга тәкъдим итү хакындагы документта шулай диелгән... Төньяк Кавказ дошманнан азат ителгәч, Мөхәммәтдиновлар дивизиясен Кырым ярым утравына күчерәләр. Гвардия дивизиясе монда да дошманны туктаусыз кыйный, яңадан-яңа позицияләр яулый. Бу канлы сугышларның алгы сызыгында һәрчак Әхмәтнур Мөхәммәтдинов була. Шундый бер һөҗүм вакытында ул каты яралана һәм аңына килми, дөньядан китә. Аңа майор дәрәҗәсе бирү турындагы документ полк штабына килә, әмма моны Әхмәтнур абый белми инде... Күмелгән урыны — Керчьтән ерак түгел урнашкан Юраков Кут дигән хутордагы туганнар каберлеге. Әхмәтнур Мөхәммәтдинов Беренче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, ике Кызыл Байрак, Александр Невский орденнары һәм уннан артык медальләр белән бүләкләнгән. Хәзер алар мәктәп музеенда саклананалар. Полк командирының хаты да шунда...

Авыл халкы арасында мондый сүзләр йөри: «Садыйк карт белән Миңнур карчыкның ике бөртек кенә баласы бар иде, сугыш башлангач, алар бөркет булып илне сакларга очтылар. Батырларча һәлак булдылар. Аларның исеме мәңгелек!» Болар — урынлы һәм гадел сүзләр.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

«НӘРСӘ ҮЗГӘРДЕ!»



4—5 мм калынлыктагы фанерадан яисә бүтән берәр каты материалдан ике түгәрәк кисеп алына. Аның берсе икенчесеннән 5—6 мм га зуррак булырга тиеш.

Ике түгәрәк тә кыл үзәктән бораy ярдәмендә тишелә, ә мәйданнары 4 тигез секторга бүленә. Кечкенә түгәрәкнең бер секторы кисеп алына, ә зурысының һәр секторына дүрт бертөсле топографик карта беркетелә. Шулай да карталарның берсе генә чын, калганнарында исә нинди дә булса топографик билге җитешми яисә артык була.

Шуннан соң кечкенә түгәрәк зурысы өстенә болт ярдәмендә беркетелә һәм әйләнеп йөри торган халәткә китерелә. Укучылар сектор эчендәге картаны җентекләп өйрәнгәннән соң, түгәрәк әйләнә һәм икенче сектор пәйда була. Уенның максаты — түгәрәкне әйләндергәннән соң, картада нәрсәләр үзгәргәнен ачыклау.

А. НОВИКОВ.

Баш мөхәррир
Роберт МИҢНУЛЛИН
Редколлегия: Шәүкәт ГАЛИЕВ, Илдар ЮЗЕЕВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләлә ГЫЙМАДИЕВА (җаваплы секретарь), Госман САДӘ (баш мөхәррир урынбасары).



«Сабантуй»ны оештыручылар — Татарстанның Халык Мәгарифе министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924 — 90 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.
Индекс — 54124. Тираж 13793



Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Телефоннар:
49-36-86, 49-36-90,
49-36-77, 49-36-88,
49-36-94, 53-57-37.

Ярдәм итәргә теләсәгез: р/счет 700161998/2345716 в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005 «Для фонда редакции».



Заказ 1815
Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты типографиясендә басылды.
Басарга кул куелды: 1995 ел, 17 апрель, 15 сәгать.